**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18 август 2026 ел № 1025

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында "Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны теркәү һәм кабул итү» муниципаль хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 27 июлендәге 802 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив хокукый актларны Россия Федерациясе Президентынының 2026 елның 20 июлендәге 498 номерлы «Укытучыларга ярдәм итү буенча өстәмә чаралар турында»гы Указына туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2026 елның 31 июлендәге 9973/26 номерлы «Мәгълүмат җибәрү турында»гы хатына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 27 июлендәге 802 номерлы «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында "Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны теркәү һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 5 июлендәге 670 номерлы, 2025 елның 10 апрелендәге 376 номерлы, 2026 елның 13 августындагы 968 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына балаларны теркәү һәм кабул итү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентында:

- Әлеге административ регламентка 8.1 кушымтасын әлеге карарның 1нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 18 августындагы 1025 номерлы карарына 1нче кушымта

**Персональ мәгълүматларны автоматлаштырылган эшкәртүгә ризалык**

Мин,________________________________________________________________,

(*ФИАи*)

паспорт________________ бирелгән________________________________________

*(серисея, номеры)* *(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)*

_____________________________________________________________________,

теркәлгән адресы:____________________________________________________,

«Шәхси белешмәләрне яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә үземнең шәхси белешмәләремне (балигъ булмаган баланың шәхси белешмәләрен)эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Мин шәхси мәгълүматларны һәм балигъ булмаган баланың ата-ана (законлы вәкил) буларак шәхси мәгълүматларын бары тик Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче һәм язылу өчен чират торган балаларның мәгълүмат базасын булдыру, шулай ук бу нәтиҗәләр турындагы мәгълүматларны электрон мәгълүмат чараларында, документаль һәм электрон формаларда саклау, шәхси мәгълүматларны автоматлаштырылган һәм автоматлаштырылмаган ысул белән җыю, системалаштыру, туплау, саклау, ачыклау (үзгәрешләрне яңарту), куллану, тарату (шул исәптән күчерү), шәхсиләштерү, блоклау, юк итү мөмкинлеге белән куллануга ризалык бирәм.

Бу ризалык минем тарафтан югарыда күрсәтелгән максатларга ирешү өчен кирәкле шәхси мәгълүматларыма (балигъ булмаган баланың шәхси мәгълүматларына) карата гамәлләр башкаруга шул исәптән (чикләүләрсез) мәгълүмат алмашу, шәхсиләштерү, блоклау гамәлләрен башкару өчен өченче якка тапшыру, шулай ук Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган башка гамәлләрне башкарубирелә.

Бу ризалык гамәлдә __________________________________

Бу ризалык минем язма үтенечем буенча теләсә кайсы вакытта кире алынырга мөмкин..

Мин мондый ризалыкны биреп, үз теләгем белән һәм үз мәнфәгатьләрем өчен эш итүемне раслыйм.

"____" _______________20_____ел. ____________ /_______________________________/